УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# ГОМУММИЛЛИ ТЕЛНЕҢ ЯШӘЕШ ФОРМАСЫ БУЛАРАК ӘДӘБИ ТЕЛҺӘМ АНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ СТИЛЬЛӘРЕ

В статье рассматриваются вопросы научного изучения функциональных стилей. По мнению некоторых ученых-языковедов функционально-стилистическая система современных развитых языков состоит в среднем из пяти функциональных стилей. Другие же ситают, что в языке, кроме разговорного, научного, официально-делового, публицистического и художественных стилей, выделяются еще обиходно-деловой, официально-документальный, церковно-религиозный стили. Существует также мнение о том, что выделение художественного и публицистического стилей в качестве самостоятельных является неверным.

**Ключевые слова:** литературный язык, функциональные стили, разговорный стиль, научный стиль, официально-деловой стиль, публицистический стиль, художественный стиль.

Тел белемендә функциональ стильләрне өйрәнү күптәннән алып барылса да, функциональ стилистика аерым фән тармагы буларак узган гасырның урталарында оеша. Аның фәнни-теоретик нигезләре А.М. Пешковский, Л.В. Щерба, Г.О. Винокур, В.В. Виноградов, Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков, И.Б. Бәширова, Ф.С. Сәфиуллина һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш таба.

XX гасыр урталарында телдә алты функциональ стиль – көндәлек-көнкүреш, көндәлек-эш, рәсми-документаль, фәнни, газета-публицистик һәм әдәби стильләр булуын күздә тота торган бүленеш киң тарала [Виноградов, 1963, с. 5–93]. Галимнәрнең бер өлеше әлеге бүленештә әдәби стиль урын алырга тиеш түгел дигән караштa торса, икенче төркем исә публицистик стильгә каршы чыга. Алар фикеренчә, вакытлы матбугатта басыла торган материаллар арасында башка стильләрнең характерлы сыйфатларын үз эченә алган текстлар да очрый, шунлыктан теге яки бу стилистик сыйфатка ия булган текстларны кайсы стильгә каратып өйрәнергә дигән сорау туа. Аерым галимнәр исә, телдә функциональ стильләр белән бергә алар эчендә подстильләрне дә аерып чыгарырга тәкъдим итәләр.

1954 елда «Вопросы языкознания» («Тел белеме мәсьәләре») журналында танылган рус галиме Ю.С. Сорокин тарафыннан стилистикага караган мәсьәләләр турында фикер алышу башлап җибәрелә. 1955 елда «Итоги обсуждения вопросов стилистики» («Стилистика мәсьәләләре белән бәйле фикер алышуның нәтиҗәләре») дип аталган мәкаләсендә В.В. Виноградов әлеге фикер алышу барлык мәсьәләләрне дә чишәргә ярдәм итмәде, ләкин фәнни җәмәгатьчелек алдында күп кенә

файдалы сораулар куйды дигән нәтиҗә ясый.

Әлеге чарада XX гасырның әйдәп баручы телче галимнәреннән барысы да диярлек катнаша. Алар арасында Г.В. Степанов, Р.А. Будагов, И.Р. Гальперин, В.Д. Левин һ.б. галимнәрне атарга була. Бүгенге көн күзлегеннән чыгып караганда, ул, һичшиксез, уңай нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, аның барышында В.В. Виноградов тарафыннан «стиль» төшенчәсенә билгеләмә бирелә, стильләрнең тарихилыгы, аларның күптөрлелеге һәм үзара мөнәсәбәте белән бәйле мәсьәләләр куела, стилистикадагы яңа юнәлешләр, аерым алганда функциональ стилистика турындагы фикерләр яңгырый. Шул рәвешле, журналдагы фикер алышуның нәтиҗәсе буларак, узган гасырның 60нчы елларында рус тел белемендә функциональ стилистика белән шөгыльләнүче бер төркем тел галимнәренең фәнни хезмәтләре дөнья күрә. Алар арасында А.Н. Васильева, Т.Г. Винокур, Б.Н. Головин, М.Н. Кожина, В.Г. Костомаров, Э.Г. Ризель һ.б. хезмәтләрен атап китәргә була.

Югарыда әйтелеп киткәнчә, кайбер галимнәр, телнең функциональ-стилистик бүленешен тагы да төгәлрәк формага китереп, стильләр эчендә подстильләрне аерып карарга тәкъдим итәләр. Мәсәлән, И.Р. Гальперин публицистик стильне ике подстильгә – газета һәм публицистика подстильләренә бүлеп карый [Гальперин, 1958, с. 383]. Газета подстиленә ул газета мәкаләсен (баш мәкаләләр, критик мәкаләләр, фельетоннар, күзәтүләр) һәм газета хәбәрен (заметка) кертә. Публицистик стильдә исә журнал мәкаләләрен, эссе һәм оратор сөйләмен аера. Күренгәнчә, И.Р. Гальперин биредә тел стильләрен түгел, ә жанрларны алгы планга чыгара.

В.Д. Бондалетов, С.С. Вартапетова кебек галимнәрнең фикеренчә, функциональ стиль – ике яклы күренеш. Ул иҗтимагый тормышның төрле өлкәләренә караган максат һәм бурычлар нигезендә барлыкка килә, ләкин шул ук вакытта ул лингвистик табигатькә ия [Бондалетов, Вартапетова ..., с. 22]. Шуңа бәйле рәвештә функциональ стильләрнең бүленеше гадәттә ике – экстралингвистик һәм лингвистик нигездә тормышка ашырыла. Бер төркем галимнәр телнең функциональ стильләрен өйрәнгәндә иң элек аралашу өлкәсенә, аралашу эчтәлегенең типологик үзенчәлекләренә, иҗтимагый аң формасына, фикерләү төренә һ.б. игътибар итәләр. Башка галимнәр шулай ук экстралингвистик факторларның мөһимлеген кире какмыйлар, ләкин тикшеренү барышында күбрәк лингвистик күрсәткечләргә – стилистик чараларга, типик стилистик сыйфатларны өйрәнүгә басым ясыйлар.

Башка галимнәр стильне нормалар системасы буларак билгелиләр. Мәсәлән, В.В. Виноградов фикеренчә, әдәби стиль – ул социаль группа яки мөстәкыйль әдәби шәхескә караган сөйләм һәм әдәби зәвык нормаларының системасы [Виноградов, 1982, с. 12–13]. Д.Н. Шмелев фикеренчә исә, без телдә булган стильләрне, аларны кулланырга

өйрәнгәннән соң, баш тартырга мөмкин булган аерым бер нормалар системасы буларак кабул итәбез [Шмелев, с. 46].

Аерым галимнәр стильне форма белән тәңгәл дип табалар. Иң мөһиме – форма турында сүз йөрткәндә тышкы калып турында гына түгел, ә бәлки эчке закончалык һәм бизәлешне дә аңларга кирәк. Телдәге стильләрне өйрәнгәндә эчтәлеккә күбрәк игътибар бирүче галимнәрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә исә тарихи, дидактик, рәсми стильләр аерылып чыгарыла [Хуринов, с. 43].

Стиль белән стилистик чараларны тәңгәлләштерү тарафдарлары булган галимнәр фикеренчә, теге яки бу стилистик элемент кайсыдыр бер стильнең характерлы үзенчәлеге булып саналырга тиеш. Мәсәлән Л.В. Щерба әдәби стильгә каршы рәсми стильне куя (1957), ә А.Н. Гвоздев рәсми һәм фәнни стильләрне бер төркемгә берләштерә (1965).

Гомумән алганда рус телендә өчтән алып җидегә кадәр функциональ стиль булганлыгы билгеләнә [Рахманин, с. 10; Андреев, с. 128]. Төрле галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән функциональ-стилистик бүленешләрдәге стильләрнең исемнәре дә аерылып торырга мөмкин. В.В. Виноградов тәкъдим иткән бүленештә, югарыда әйтелеп киткәнчә, алты стиль аерылып чыгарыла. Шул ук вакытта, әлеге алты стиль арасындагы көндәлек-эш һәм рәсми-документаль стильләрне берләштереп карау тенденциясе бар [Гальперин, 1981; Кожина, 1977]. Рус тел белемендә тагын бер стиль – дини стильне аерып чыгаручы галимнәр дә бар [Кожина, 2008, с. 285]. Татар тел белемендә И.Б. Бәширова дини-дидактик стильне шулай ук мөстәкыйль стиль буларак аерып чыгару ягында [Бәширова, с. 20–25].

Сөйләмә стиль көндәлек сөйләмдә кулланыла, ләкин аерым очракларда ул язма формаларда да чагылыш таба, мәсәлән, шәхси хатларда. Сөйләмә стиль аралашу функциясен үти, автор рәсми булмаган сөйләшү вакытында әйләнә-тирәдәгеләргә үзенең уй-фикерләрен җиткерә, көндәлек мәсьәләләр буенча фикер алыша. Әлеге сөйләшү барышында гадәттә гади сөйләм лексикасы кулланыла. Сөйләмә стиль диалог, шәхси хатлар, телефоннан сөйләшү кебек жанрларда актив кулланыла.

Фәнни стиль – иҗтимагый үзаңның бер формасы булган фән белән тыгыз бәйләнештә тора. Фәнни текстлар берничә төркемгә бүленә. Алар арасында иң киң таралганнары – махсус (профессиональ публикага юнәлдерелгән) һәм фәнни-популяр (төрле катлам укучылар өчен) текстлар. Әлеге стильнең максаты – фән өлкәсенә караган күренешләрне һәм законнарны аңлату, ачышларны тасвирлап бирү, өйрәтү һ.б. Фәнни стиль гадәттә фәнни мәкалә, дәреслек, монография кебек жанрларда язма монологик формада чагылыш таба.

Рәсми-эш стиле сәяси, дипломатик, коммерция, юридик һ.б. характердагы документларда урын ала. Әлеге документларның текстларына императивлык, төгәллек, стандарт лексик

формалар һәм терминнарның кулланылуы, эмоцияләрнең урын алмавы хас. Рәсми стильнең төп функциясе – хәбәр итү, ә төп яшәеш формасы – язма форма. Бу – мәгълүматны документлаштыру зарурлыгы белән бәйле.

Публицистик стиль аралашу һәм тәэсир итү функцияләренә ия булуы белән аерылып тора. Публицистик текстлар халыкка язма яки сөйләмә формадагы мәгълүмат чаралары аша җиткерелә, аларның язма формалары гадәттә мәкалә, очерк, репортаж, фельетон, интервью жанрларында чагылыш җаба. Функциональ-стилистик күзлектән чыгып караганда, үзенең күпкырлы максат-бурычларына бәйле рәвештә, публицистик стиль иң катлаулы стильләрдән санала.

Әдәби стиль матур әдәбият жанрларында чагылыш таба. Ул телнең барлык лексик байлыгын, башка стильләрнең мөмкинлекләрен файдаланып, авторның фикер һәм тойгыларын укучыга җиткереп, аңа йогынты ясый. Л.Ю. Максимов, Н.М. Шанский, Д.Н. Шмелев кебек галимнәр фикеренчә, әдәби стильдә башка стиль үзенчәлекләре зур урын алып тора, шул сәбәпле әдәби стильне мөстәкыйль стиль буларак аерып чыгару дөрес булмый. Алар фикеренчә, әдәби тел кысаларында, бернинди дә стильгә бәйләп карамыйча, мөстәкыйль бер күренеш – «әдәби әсәр теле»н аерып чыгару дөресрәк була. Башка бер төркем галимнәр (В.В. Виноградов, А.И. Ефимова, Р.А. Будагов) исә әдәби әсәрләр телен аерым стиль буларак кабул итәләр һәм аны «эстетик-коммуникатив стиль» дип атыйлар.

Шулай итеп, функциональ стилистика рус тел белеменең мөстәкыйль тармагы буларак XX гасырның 50 нче елларында барлыкка килә. Соңрак рус тел белеме казанышларына нигезләнеп, татар теленең функциональ-стилистик бүленеше дә өйрәнелә башлый. Кайбер галимнәр фикеренчә, бүгенге көндә алга киткән телләрнең функциональ-стилистик системасы, нигездә, биш стильдән оеша. Шул ук вакытта сөйләмә, фәнни, рәсмиэш, публицистик һәм әдәби стильләр белән бергә көндәлекэш, рәсми-документаль һәм дини стильләрне аерып чыгаручы галимнәр дә бар. Аерым галимнәр исә телнең функциональ-стилистик системасына әдәби һәм публицистик стильләрне кертеп карамау яклы. Шул рәвешле, функциональ стилистика өлкәсендә бүгенге көндә дә ачыкланып бетмәгән мәсьәләләр кала бирә.

## Әдәбият

*Андреев Н.Д.* Статистико-комбинаторные методы в теоретическом и прикладном языкознании. Л.: Наука, 1967. 404 с.

*Бондалетов В.Д., Вартапетова С.С., Кушлина Э.Н., Леонова Н.А.* Стилистика русского языка. Л.: Просвещение, 1982. 286 с.

*Бәширова И.Б.* Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Казан, 2005. 30 б.

*Виноградов В.В.* Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. М.: АН СССР, 1963. 256 с.

*Виноградов В.В.* Очерки по истории русского литературного языка XII–XIX веков. М.: Высшая школа, 1982. 528 с.

*Гальперин И.Р.* Очерки по стилистике английского языка. М.: Издательство литературы на иностранных языках, 1958. 462 с.

*Гальперин И.Р.* Текст как объект лингвистического исследования. М.: Наука, 1981. 140 с.

*Кожина М.Н.* Стилистика русского языка. М.: Просвещение, 1977. 223с.

*Кожина М.Н., Дускаева Л.Р., Салимовский В.А.* Стилистика русского языка. М.: Флинта: Наука, 2008. 464 с.

*Рахманин Л.В.* Стилистика деловой речи и редактирование служебных документов. М.: Высшая школа, 1997. 239 с.

*Хуринов В.В.* Функционально-стилистическая дифференциация англоязычных научных и газетно-публицистических текстов (на мат. англ. языка): дис. … канд. филол. наук. Москва, 2009. 272 с.

*Шмелев Д.Н.* Русский язык в его функциональных разновидностях. М.: Наука, 1977. 168 с.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителде*

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*